**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.07.2018 г.Мензелинск № 753

Суд тарафыннан эшкә яраксыз яисә өлешчә яраксыз дип табылган балигъ булмаганнарга карата опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә административ регламентларны раслау турында

27.07.2010 елдагы “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы №210-ФЗ Федераль законын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасының 20.03.2008 елдагы “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарын опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасында аерым дәүләт вәкаләтләре бирү турында”гы №7-ЗРТ Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 17.04.2015 елдагы “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшкәртү һәм раслау Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында”гы №259, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 26.02.2016 елдагы “Административ регламентларга үзгәрешләр кертү турында”гы №358, 24.04.2008 елдагы “Опека һәм попечительлек турында”гы №48-ФЗ Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 17 ноябрендәге “Эшкә яраксыз яисә өлешчә эшкә яраксыз балигъ булмаганнарга карата опека һәм попечительлекне башкаруда аерым мәсьәләләр турында”гы №1221 Карары нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты

КАРАР ЧЫГАРА:

1.Яңа редакциядә расларга:

1.1.Стационар формада социаль хезмәтләр күрсәтүче социаль учреждениеләргә карау астындагыларны юнәлтү турында карарлар бирү

буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламенты (кушымта №1).

1.2. Суд тарафыннан эшкә яраксыз яисә өлешчә яраксыз дип табылган балигъ Булмаган затка опекун яки попечитель билгеләү һәм опека һәм попечительлек билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (Кушымта№2).

1.3. Карау астындагылар мәнфәгатьләрендә гомерлек рента килешүе төзергә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә административ регламент (Кушымта№3).

1.4. Балигъ булмаган эшкә яраксыз зат мәнфәгатьләрендә торакны приватизацияләүгә опекунга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә административ регламент (Кушымта№4).

1.5. Карау астындагы затның торагын опекунга наемга бирүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә админитратив регламент (Кушымта№5).

1.6. Карау астындагыларның милкен сатуга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә административ регламент (Кушымта №6).

1.7. Яшәү урынын үзгәртүгә бәйле рәвештә, карау астындагы затны яшәү урыныннан исәптән төшерүгә опекунга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә административ регламент (Кушымта №7).

1.8. Карау астындагы затның милкенә хокук гамәлгә керүгә опекунга яисә попечительгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә административ регламент (Кушымта №8).

1.9. Карау астындагы затның саклык счетыннан файдалануга хокук гамәлгә керүгә опекунга яисә попечительгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә административ регламент (Кушымта №9).

1.10. Суд тәртибендә эшкә яраксыз дип табылган балигъ булмаган затны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнарның гаиләләренә вакытлыча тапшыру турында нәтиҗә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә административ регламент (Кушымта №10).

2. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесенең 21.06.2016 елдагы "Суд тарафыннан эшкә яраксыз яисә өлешчә яраксыз дип табылган балигъ булмаганнарга карата опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә административ регламентларны раслау турында"гы №647 Карарын көчен югалткан дип санарга.

3. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесенең 19.06.2018 елдагы "Суд тарафыннан эшкә яраксыз яисә өлешчә яраксыз дип табылган балигъ булмаганнарга карата опека һәм

попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә административ регламентларны раслау турында”гы №625 Карарын көчен югалткан дип санарга.

4. Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты гомуми бүлегенең баш белгеченә өч эш көне эчендә гамәлдәге Карарны Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

5.Гамәлдәге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Н.Г.Бикеевага йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы А.Г.Гатина.